# МИН ГАРМУН БУЛЫР ИДЕМ

*ФАСИЛ ӘХМӘТОВ   музыкасы*
*ФАИЛ   ШӘФИГУЛЛИН   сүзләре*

Көмеш йолдызлар яуганда,
Шаулаган чакта иген,
Тәрәзәндә ут янганда,—
Мин гармун булыр идем.

*Кушымта:*
Мин гармун булыр идем,
Назлы жыр көйләр идем;
Хисләремне моң телендә
Тик сиңа сөйләр идем.

Чыңлар идем өй артында,
Моңсыз узалмас идем,
Тыңлар идең син дә чыгып,
Чыкмый түзәлмәс идең.

*Кушымта.*

Йөрәгеңдә урын тапсаң
Минем кайнар хисләргә,
Тальян гармун булыр идем
Жәйге зәңгәр кичләрдә.

*Кушымта.*